ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.02.2018 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 217**

Зеленодольск муниципаль районында
кече һәм урта эшкуарлык субъектларына
ярдәм итү чаралары турында

Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү максатында һәм Зеленодольск муниципаль районы Советының «Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2017 елның 12 октябрендәге 242 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольскмуниципаль район Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2018-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» чаралары («юл картасы») планын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары С.В. Кадыйровага йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

**«2018-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» чаралары («юл картасы») планы**

1. «2018-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» чаралары («юл картасы») планы тасвирламасы.

Кече һәм урта эшкуарлык Зеленодольск муниципаль районы хуҗалыкларының икътисадый системасының аерылгысыз һәм бик мөһим өлеше булып тора. Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, нәтиҗәле конкурентлы икътисад, халыкның югары тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын тәэмин итүче эш урыннары булдыруга туры килгән базар хуҗалык итү системасының аерылгысыз элементы, район бюджетының керем өлешен тулыландыру ысулларының берсе буларак карала. Килеп туган икътисадый хәлне исәпкә алып, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү проблемасы актуаль генә түгел, ә Зеленодольск муниципаль районының икътисадый потенциалын саклауда һәм үстерүдә төп проблемаларның берсе булып тора.

Финанс тотрыксызлыгы шартларында Зеленодольск муниципаль районында кече эшкуарлыкка карата дәүләт-иҗтимагый сәясәтен формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда беренче планга кече һәм урта эшкуарлык субъектлары санын һәм аларда булдырылган эш урыннарын саклап калу гына түгел, ә бу күрсәткечләрне арттыру бурычы да куелды.

«2018-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» чаралары (алга таба - «юл картасы») планын гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны нәтиҗәле үстерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

2. «Юл картасы»ның максатлары һәм бурычлары.

«Юл картасы»ның максатлары булып түбәндәгеләр тора:

- кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә өстәмә эш урыннарын булдыру;
- кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә хезмәткәрләр санын арттыру;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының тотрыклы үсешен тәэмин итү;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эшчәнлегеннән район бюджетына салым җыемнары үсеше;

«Юл картасы»ның куелган максатларына ирешү һәм аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен тәэмин итү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының финанс-кредит ресурсларына һәм кече һәм урта бизнес буенча дәүләт ярдәме программаларына керүен тәэмин итү;
- ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар инфраструктурасына кече бизнесның керүен тәэмин итү;

-төбәк базарларына кече һәм урта эшкуарлык субъектларын алга җибәрү өчен оештыру буенча булышлык күрсәтү; (кече һәм урта эшкуарлык өчен күргәзмә - ярминкә эшчәнлеген оештыру);

-кече һәм урта эшкуарлыкның уңай имиджын булдыру;

- дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта бизнес (эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре), оешмалар, җәмәгатьчелек арасында мәгълүмати үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү.

Зеленодольск муниципаль районында югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итүнең төп юнәлеше кече һәм урта бизнес өчен «оазислар» - сәнәгать мәйданчыклары, индустриаль парклар, бизнес-парклар булдыру, беренче чиратта, алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе (ТОСЭР) кысаларында.

Моннан тыш, кече һәм урта бизнес ярдәменең төп юнәлеше Зеленодольск муниципаль районының туристлык җәлеп итүчәнлеген арттырачак һәм туристлык хезмәтләре базарын үстерү.

«Юл картасы» мәсьәләләрен хәл итүгә китерәчәк «юл картасы» чаралары планы исемлеге «юл картасы»ның 1 нче кушымтасында китерелә.

3. «Юл картасы»чаралар планын гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре.

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә «юл картасы» чаралары планын гамәлгә ашыру кече һәм урта эшкуарлык субъектлары санын арттырырга, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә яңа эш урыннары булдырырга, эшкуарлык климатын булдырырга, эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын арттырырга мөмкинлек бирәчәк. «Юл картасы» чаралары планын гамәлгә ашыруның максатчан күрсәткечләре:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кече һәм урта бизнес( МСБ) субъектлары саны, данә | | | |
| | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| | 5056 | 5100 | 5150 | 5200 |
| 2 | Эшчеләр саны, кеше. | | | |
| | 7000 | 7400 | 7600 | 8000 |
| 3 | ВТПда МСБ өлеше, % | | | |
| | 21,5 | 22 | 24 | 25 |
| 4 | Җирле бюджетка салым кертемнәрендә МСБ өлеше, % | | | |
| | 20,3 | 20,8 | 21 | 22 |

1 нче кушымта

**«Юл картасы» чаралары планы**

| **№** | **Чара** | **Башкаручылар** | **Башкару срогы** | **Чыккан документ** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү инфраструктурасын үстерү** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1.1 | Бизнесны ачу, алып бару һәм үстерү мәсьәләләре буенча эшкуарларны консультацияләү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 1.2 | Кече эшкуарлык субъектлары реестрын булдыру һәм аны актуаль хәлдә тоту | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 1 кв. 2018 ел | - |
| 1.3 | Кече эшкуарлыкка ярдәм мәсьәләләре буенча уку-укыту семинарлары оештыру | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| **2. Инженерлык инфраструктурасы объектларын төзү һәм инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кече һәм урта бизнесның кирәкле ресурсларга керү системасын яхшырту** | | | | |
| 2.1 | Сәнәгать мәйданчыкларын булдыру һәм үстерү | ЗМР БК икътисад бүлеге; «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 ел | ЗМР советы карары. Башкарма комитет җитәкчесе карары |
| 2.2 | Инженерлык челтәрләренә тоташтыру мәсьәләләрен хәл итүдә консультация бирү һәм ярдәм итү. | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 ел | - |
| 2.3 | МСБ бирү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген актуальләштерү | ЗМР ПИЗО; «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Һәр елның 2 кв. | Башкарма комитет җитәкчесе карары |
| 2.4 | Хуҗасыз күчемсез милек объектларын актуальләштерү | ЗМР ПИЗО; «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Һәр елның 2 кв. | - |
| 2.5 | Кызыксынучы кече һәм урта эшкуарлар субъектларына тулыландыру һәм тапшыру өчен хуҗасыз ихтыяҗ булмаган авыл хуҗалыгы җирләрен актуальләштерү | ЗМР ПИЗО; «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Һәр елның 2 кв. | - |
| **3.Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына финанс ярдәме чараларын гамәлгә ашыру** | | | | |
| 3.1 | Татарстан Республикасы Икътисад һәм авыл хуҗалыгы министрлыгы | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ; ЗМР авыл хуҗалыгы | - | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тарафыннан гамәлгә ашырыла торган федераль һәм региональ программаларда катнашу өчен конкурс документациясен әзерләүдә эшкуарларга ярдәм итү | идарәсе | | |
| 3.2 | «Авылда эшлекле активлыкны үстерү» чаралары планын эшләү һәм актуальләштерү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 елның 1 кварталы | |
| 3.3 | ЗМР муниципаль заказчылары тарафыннан МСБ субъектлары продукциясенә ихтыяҗлары булу турында аларга мәгълүмат бирү. МСБ субъектларын ЗМР муниципаль контрактларында катнашу өчен документлар әзерләүдә консультацияләү. | «Муниципаль заказ дирекциясе» МБУ | Даими | |
| 3.4 | ЗМР җитештерүчеләре - МСБ субъектлары продукциясенең бердәм каталогын булдыру һәм аны ел саен актуальләштерү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 ел, 2 кв. м. алга таба ел саен | |
| **4. Кече һәм урта бизнес субъектлары өчен административ процедураларны гадиләштерү** | | | | |
| 4.1 | Эшмәкәрләрнең дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары белән очрашуларын оештыру | ЗМР БК<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Ярты елга бер тапкыр | - |
| 4.2 | Эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы эшен алып бару | Кече һәм урта бизнесны үстерү буенча координация советы<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 4.3 | Төзелешкә рөхсәт бирү срокларын җиткерү, тораклан торак булмаган урынга күчерү, ТР МК һәм | ЗМР БК | - | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | АСИның "иң яхшы тәҗрибәләре" нә кадәр реклама урнаштыруга рөхсәт бирү срокларын тулыландыру | | | |
| 4.4 | ЗМР административ комиссиясе составына эшкуарлык буенча координацион совет вәкилләрен кертү | ЗМР Советы;<br>ЗМР БК | | ЗМР советы карары<br>Башкарма комитет җитәкчесе карары |
| **5.Инвестицион проектларны гамәлгә ашыру кысаларында административ киртәләрне бетерү** | | | | |
| 5.1 | Инвесторларның дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары белән очрашуларын оештыру | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 5.2 | Инвестиция проектларын этаплап алып бару | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| **6. Салым йөкләмәсен киметү** | | | | |
| 6.1 | К2 база кеременең төп коэффициентын үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләү | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Һәр елның 4 кварталы | ЗМР советы карары |
| **7. Бизнес алып бару һәм инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен инвестицион җәлеп итүчән территория буларак, Зеленодольск муниципаль районын алга этәрү буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру.** | | | | |
| 7.1 | Гамәлгә ашырыла торган программалар һәм чаралар турында массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат урнаштыру | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.2 | Потенциаль инвесторларга публикацияләр һәм инвестиция тәкъдимнәре әзерләү | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.3 | Потенциаль инвесторларны максатчан эзләү һәм сөйләшүләр уздыру | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.4 | Федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге конференцияләрдә һәм | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция | Даими | - |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күргәзмәләрдә катнашу. | үзәге» ЗМР АУ | | |
| 7.5 | Татарстан Республикасыннан читтә эшкуарларга эшлекле элемтәләр урнаштыруда ярдәм итү | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.6 | Зеленодольск муниципаль районының Инвестиция порталын алып бару һәм алга җибәрү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.7 | Инглиз, кытай һ.б. чит телләрдә инвестиция потенциалына презентация булдыру | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 1 кв. 2018 ел | |
| **7.8** | **ЗМРның туристлык буенча җәлеп итүчәнлеген арттыру** | | | |
| 7.8.1 | Муниципаль туристлык маршрутларын эшләү һәм алга җибәрү:<br>-Раифа буенча җәяү йөрү;<br>«Шүрәле янында кунакта» маршруты | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 елның 2 кварталы | - |
| 7.8.2 | Районның туристик брендларын эшләү һәм алга җибәрү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 ел | - |
| 7.8.3 | ЗМР һөнәрчеләре һәм предприятиеләре белән сувенир продукциясе җитештерү буенча эш һәм аны алга җибәрү | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018-2019 ел | - |
| 7.9 | Зеленодольск массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә эшкуарлыкның уңай образын алга җибәрү | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | Даими | - |
| 7.10 | Бизнесның рәсми булмаган клубын оештыру | «Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | - | - |
| 7.11 | МСБ мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр өчен аноним элемтә каналы булдыру | ЗМР БК;<br>«Зеленый Дол»инвестиция үзәге» ЗМР АУ | 2018 елның 2 кварталы | - |